КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 11 гыйнвар г.Казань № б-18

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 июль, б-1705 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 15 ноябрь, б-2556 нчы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб составында:

оператив штаб составыннан Ф.У.Мөхәммәтҗановны чыгарырга;

оператив штаб составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары Александр Васильевич Мищихинны (килешү буенча) кертергә;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын транспорт белән тәэмин итүне һәм логистиканы оештыру буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Ф.У.Мөхәммәтҗановны чыгарырга;

эшче төркем составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Рамил улы Гариповны кертергә (килешү буенча);

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирының клиентлар төркемнәрен урнаштыру, ашату буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Ф.Н.Фәизовны чыгарырга;

эшче төркем составына «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Эчке эшләр министрлыгының Хуҗалык һәм сервис белән тәэмин итү үзәге» федераль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Юрий Николаевич Колпаковны кертергә (килешү буенча);

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын үткәрү кысаларында федераль, төбәк һәм муниципаль хакимият органнарын аккредитацияләү һәм аларның хезмәттәшлеген оештыру һәм беркетмә белән тәэмин итү буенча эшче төркем составында:

исемендә «аккредитацияләү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

эшче төркем составыннан Д.Р.Әминовны, Л.З.Мазуновны, В.В.Михайловны чыгарырга;

эшче төркем составына «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең югары вазыйфаи затлары иминлеген тәэмин итү үзәге башлыгы урынбасары Александр Александрович Макуринны (килешү буенча) кертергә;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирының комплекслы куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Ф.У.Мөхәммәтҗановны чыгарырга;

эшче төркем составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары Александр Васильевич Мищихинны (килешү буенча) кертергә;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын финанс белән тәэмин итү һәм аның дәүләт мөлкәтен файдалану мәсьәләләре буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Ф.Н.Фәизовны чыгарырга;

эшче төркем составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының финанс белән тәэмин итү үзәге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Альберт Галәметдин улы Кәримуллинны (килешү буенча) кертергә;

әлеге боерык белән расланган Видеоуеннар уйлап чыгаручыларның халыкара форумын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составын төшереп калдырырга;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын ачу һәм ябу тантанасын әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Ф.У.Мөхәммәтҗановны чыгарырга;

эшче төркем составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары Александр Васильевич Мищихинны (килешү буенча) кертергә;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын үткәрү кысаларында аккредитация буенча эшче төркем төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын үткәрү кысаларында «Уенны башла» бөтенроссия конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 гыйнвар, б-18 нче
боерыгы белән расланды

2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын үткәрү кысаларында аккредитация буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, (килешү буенча), эш төркеме җитәкчесе (килешү буенча) |
| Михайлов Владимир Валерьевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры киңәшчесе (килешү буенча), эшче төркем җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Әминов Денис Равил улы | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасының аккредитация идарәсе җитәкчесе, эшче төркем секретаре (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Аникина Наталья Николаевна | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Шәхси составы белән эшләү идарәсенә караган кадрлар бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Астафьев Игорь Владимирович | «Казань Экспо» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директорының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Гречанникова Наталья Вадимовна | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе проректоры (килешү буенча) |
| Исаенков Александр Викторович | Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкиле (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Макурин Александр Александрович | «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең югары вазыйфаи затлар иминлеген тәэмин итү үзәге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Низамиев Марат Фәрид улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы урынбасары |
| Хәйруллин Руслан Фәрхәт улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләр эшчәнлеген тәэмин итү һәм оештыру эшләре бүлеге мөдире |
| Хаярова Алсу Рәүф кызы | «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесенең конференция хезмәтләре бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Яруллин Салават Мөнир улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт беркетмәсе идарәсе башлыгы урынбасары – оештыру-беркетмә бүлеге мөдире (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 гыйнвар, б-18 нче
боерыгы белән расланды

2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын үткәрү кысаларында «Уенны башла» бөтенроссия конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Садыйков Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Яковлев Альберт Валерьевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Әхмәров Айрат Рәиф улы | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасының социаль проектлар идарәсе җитәкчесе, эшче төркем секретаре (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Агафонов Алексей Васильевич | «Россия – мөмкинлекләр иле» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директорының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Вандюков Дмитрий Владимирович | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Власов Руслан Игоревич | «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Мещеряков Роман Константинович | «Мәгълүматлаштыруны координацияләү һәм экспертиза үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең проект администраторы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Парецкая Ирина Александровна | Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының Цифрлы компетенцияләрне үстерү һәм мәгариф департаменты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Прокуронов Владимир Александрович | «Цифрлы икътисад» коммерциягә карамаган автоном оешмасының проектлар җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сәгыйтова Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Садыйков Айрат Халит улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улы | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры. |